*сүз ишетсәләр, шуны таратып йөрүчеләр, дип җавап бирерләр».* Моңа шулай сүгенү дә керә. Пәйгамбәребез әйтте: *«Анасы, атасы белән сүгенүчеләргә ләгънәт булсын».* Һәрчак әдәби телдә сөйләшергә кирәк. Хәтта яман, чирканыч авырулы кешеләр турында да, аларның исемнәрен атамыйча, аларны рәнҗетмәслек итеп йомшаграк сөйләргә тиешбез.

### Ләгънәт кылу

Мөселманнар кешеләрне дә, хайваннарны да, башка төрле нәрсәләрне дә ләгънәтләргә тиеш түгел. Пәйгамбәребез әйтте: *«Мөэмин булган ләгънәт итмәс».* Сәфәр вакытында бер ханым дөягә ачуланып, аны ләгънәтләде. Пәйгамбәребез ул хатынга: *«Дөядән әйберләрне ал да аны җибәр, ул мәлгунь булды»,* – диде. Ул дөягә башка берәү дә якынлашмады. Билгеле бер кешегә ләгънәт кылу ярамый, әмма яман төркемгә, мәсәлән, залимнәргә, кәферләргә вә фасикъларга ләгънәт булсын дияргә ярый. Шулай ук кәфер булып үлгән кешеләргә ләгънәт укырга ярый. Мәсәлән, Фиргавенгә, Әбу Җәһелгә. Әмма яһүдиләргә ләгънәт укырга ярамый, чөнки аларның үлгәнче иман китерүләре һәм аларның ләгънәт итүчедән дә хәерлерәк булулары мөмкин. Монда сорау туарга мөмкин: мөселманнарга, Аллаһының рәхмәте булсын, дип әйтәбез бит, бәлки, алар да үлгәнче кяфер булырлар, ни өчен хәзерге вакытта кяфер булучыларга ләгънәт укырга ярамый? Рәхмәт сүзенең мәгънәсе Аллаһы сине рәхмәте белән мөселманлыкта дәвамлы кылсын дигәнне белдерә. Ләгънәт кылу исә, Аллаһы сине көфердә дәвамлы кылсын дигәнне белдерә. Әгәр бер кеше гомер буе шайтанга ләгънәт әйтмәгән булса, кыяматтә аннан ни өчен ләгънәт итмәдең дип сорамаслар. Әмма ул берәр кешегә ләгънәт кылган булса, аннан бу турыда сораулары ихтимал.

### Әйткән сүзне үтәмәү

Пәйгамбәребез әйтте: *«Өч нәрсә бар, берәүдә боларның өчесе дә булса, ул намаз укыса һәм ураза тотса да, монафыйк булыр. Сөйләсә ялган сөйләр, вәгъдәсен бозар, әманәткә хыянәт итәр».* Вәгъдәгә туры булу - фарыз гамәл. Берәү әйтте: “Пәйгамбәребез белән фәлән җирдә очрашырга сүз куешкан идек. Мин сүземне онытттым. Өченче көн ул җиргә барсам, Пәйгамбәребез ул җирдә тора иде. Ул өч көннән бирле сине көтәм, диде”. Галимнәр әйтүенчә, бер кеше белән очрашырга сүз куешсагыз, намаз вакыты кергәнче көтәргә кирәк.

### Ялган сөйләү

Бу олугъ гөнаһлардан. Пәйгамбәребез әйтте: «Ялган сөйләү монафыйклык ишекләреннән берседер». Янә әйтте: *«Бәндә ялган сөйли-сөйли шундый дәрәҗәгә ирешер ки, Аллаһы Тәгалә каршында аны ялганчы дип язарлар».* Янә әйтте: *«Ялган сөйләү ризыкны киметер».*

Абдуллаһ бин Җәрад Пәйгамбәребездән: «Мөэмин кеше зина кылырмы?» – дип сорады. «Бәлки, кылыр», – диде ул. «Ялган сөйләрме соң?» – дип сорады. Пәйгамбәребез: «Юк, сөйләмәс», – диде һәм Коръәннән: *«Фәкать иман китермәгәннәр генә ялган сөйләр»,* – дигән аятьне укыды. Абдуллаһ бин Гамир сөйләгән: «Кечкенә чагымда уйнарга китеп бара идем, әнием миңа: *«Кил әле, бер әйбер бирәм»,* – диде. Рәсүлуллаһ аңа: «Нәрсә бирәсең», – диде. Әнием: «Хөрмә бирәм, йә Рәсүлуллаһ», – диде. Рәсүлуллаһ: «Әгәр бирмәсәң, сине ялганчы дип язарлар», – диде. Рәсүлуллаһ әйтте: *«Сезгә иң олы гөнаһларны белдеримме? Аллаһыга ширек кату һәм ата-ананы рәнҗетү. Тагын да ялган сөйләү. Фәрештәләр ялган сөйләүченең сасысыннан бер мил ераклыкка качарлар»,* – диде.

Шул сәбәпле, сөйләшкәндә төчкерү, сүзнең дөреслегенә дәлил, диләр. Чөнки хәдистә әйтелгәнчә: *«Төчкерү фәрештәдән, иснәү шайтаннан».* Әгәр сүз ялган булса, фәрештә якын булмас һәм төчкерү дә мөмкин булмас. Пәйгамбәребез әйтте: *«Хыянәт һәм ялганнан башка бөтен сыйфатлар да мөэминдә булырга мөмкин».*

*(“Мөселман календаре”ннан)*

## Гөнаһтан ерак булыр өчен

Бер гөнаһлыга үкенү һәм тәүбәдән соң үз гөнаһлары язылган исемлекне бирәләр дә укырга кушалар. Гөнаһ иясе гаебен таныл үксеп елый башлый, хәтта язуны да танымас дәрәҗәгә җитә. Чын күңелдән тамган күз яшьләре аның язуыннан гөнаһларын юып алалар, һәм ул алардан арына, арулана. Шулай итеп, ул гафу ителә.

Иң беренче гөнаһ кылучылар - Адәм галәйһи вә сәлләм һәм аның хатыны. Һәм беренче тәүбә догасы алар өчен җибәрелә. «Әл-Әгъраф» сүрәсендәге 23 нче аятьтә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аларның сүзләрен иңдерә: *«Йә Раббым! Без үзебезгә үзебез гаделлек күрсәтмәдек, әгәр син безне ярлыкамасаң һәм безгә рәхимле булмасаң, без зарар күрүчеләр рәтендә булырбыз»,* – диелә. Бу дога киләчәк буынга да кыямәт көненә чаклы тәүбә догасы булып тора.

Башка сүрәдә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә үзенең колларына: *«Әй, иман китерүчеләр! Аллаһы каршында чын күңелдән тәүбә итегез! Бәлки, шул вакыт Раббыгыз сезнең гөнаһларны каплар»* («әт-Тәхрим» сүрәсе, 8 нче аять). Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә үзе колларын дөрес итеп дога кылырга өйрәтә. «Әәл Гыймран» сүрәсендә: *«Йә Аллаһы! Безне тугры юлга күндергәч, йөрәкләребезне тугрылыктан читләштермә. Үзеңнән безгә мәрхәмәт бүләк ит. Син – бүләкләүче!»* – диелә.

Бик күп аятьләрендә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә үзенең колларын чын күңелдән тәүбә итсәләр, ярлыкауны сорасалар, гөнаһларын гафу итәчәген әйтә.



*«Кем дә кем ялгыш адым ясый яки гаделсезлек кыла һәм Аллаһыны искә алып, гөнаһларын кичерүне сорый – Аллаһыдан башка кем тагын гөнаһларны кичерә? һәм тагын гөнаһ эшләүдән тыела икән, ул кешегә Ходайдан бүләк булып ярлыкау һәм чишмәләре белән җәннәт бакчасы булачак. Хәерле гамәл кылганнарга әнә шундый бүләк»* («Әәл Гыймран», 135-136 нчы аятьләр).

Әгәр дә берәрсе үкенү кичереп, кылган хаталарын кабатламый икән, аларның гөнаһларын Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә рәхмәт белән алыштырыр: *«...кем тәүбә итә һәм изгелек кыла икән, Аллаһы аларның явыз эшләрен изге гамәлләргә алыштырыр, чөнки Аллаһы – Гафу итүче һәм Рәхимле»,* диелә «Фуркан» сүрәсенең 70 нче аятендә.

Тәүбә итү турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ошбу хәдисен тәкъдим итәргә мөмкин: *«Кем дә кем үзенең гөнаһлары өчен гафу үтенеп, Аллаһыга мөрәҗәгать итә, ул кешегә Раббыбыз чарасыз хәлләрдән дә юлын күрсәтер, авырлыкта җиңеллек бирер һәм ризык кирәксә – ризыкландырыр».*

Бервакыт Хәсән Басри дигән җитәкче янына дүрт кеше: берсе – корылыкка, икенчесе – ярлылыкка, өченчесе – уңыш булмауга, дүртенчесе баласызлыкка зарланып килә. Имам аларны тыңлап, кылган гамәлләре өчен гафу үтенергә куша. Киңәш сораучылар:

– Хөрмәтле, безнең һәрберебезнең үз борчуы, ә сез ни өчен бер киңәш бирәсез? – ди.

Хәсән Басри әйтә:

– Аллаһыдан тәүбә-истигъфар итүен сорагыз, Ул – гафу итүче. Ул – сезгә яңгыр яудыручы, бакча һәм елгалар, балалар Аллаһының рәхмәте белән булыр («Нух» сүрәсе, 10-12 нче аятьләр).

«Әш-Шугара» сүрәсенең 40нчы аятендә: *«Сезгә килгән һәр кайгы – үзегезнең кылган гамәлләрегез нәтиҗәсе»,* – диелгән.

Нинди гамәлләр кайгыга китерә? Бу – гөнаһ эшләр. Кечкенә һәм зур гөнаһлар, йөрәк гөнаһы, күз, тел, колак, кул-аяк һәм бөтен тән гөнаһлары була. Иң зур гөнаһ – Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә гафу итми торганы – күп аллалык һәм Аллаһыга ышанмау. Бер хәдисендә Пәйгамбәребез: *«Сезне юкка чыгаручы җиде куркыныч гөнаһтан сакланыгыз: Аллаһыга тиң илаһ бар диюдән, сихер белән шөгыльләнүдән, гаепсезне үтерүдән, ятимнәрнең малына кул сузудан, рибадан, сугыш кырыннан качудан, зинада гаепләнүдән»,* – ди.

Нәфескә буйсынып, колларны тиеш түгел гамәл кылуга сузу күптән билгеле. Нәкъ нәфес безне тыелганны эшләүгә этәрә дә. Кешелекнең үлмәс дошманы – шайтан яхшы гамәлгә каршы котыртучы булып санала. Һәм безгә гөнаһ кылу, нәфескә буйсыну кебек гамәлләрдән саклану өчен үз-үзебез белән көрәшергә туры килә. һәм «нәрсә эшләргә кирәк»лек хакында тулы бер исемлек төзелә:

- Күзләрне тыелганнан качырырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Файдасыздан качу – мөселманны бизәүче асыл сыйфат»,* – ди.

- Телне гайбәттән, ялганнан, үз-үзеңне мактау һәм икейөзләнү кебек гамәлләрдән сакларга. Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә зикер әйтү, изге, файдалы, дөрес сүзләр сөйләүгә юнәлдерергә.

- Хәрәм ризык һәм күп ашаудан (кирәгеннән артык) тыелырга.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Кем гөнаһ эшләүне күрә икән, ул аны төзәтсен, хәленнән килмәсә, тел белән кисәтсен, алай да хәленнән килмәсә – күңеле, йөрәге белән каршы булсын»,* – ди.

Адәм баласына ни эшләргә кала? Гөнаһтан сакланырга. Үзенең кылган хата-гөнаһларын изгелек, дога белән төзәтергә. Кирәк икән, яшәү урынын үзгәртергә – үз дине, әхлак сыйфатларына, белеменә туры килә торган кабилә янына күчәргә. Еш һәм аңлап (асылына төшенеп) Коръән укырга. Үз гамәлләреңә җавап бирергә һәм һәр көн, адым саен гөнаһтан ераклашырга кирәк.

**Сәрия ЗАКИРОВА.**
*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

***БӘЕТ***

**Минем бертуган Халисә апамның биш улы. Җизнәбез үлгәнгә 9 ел булды. Икенче улы Рамил 47 яшендә кинәт кенә урындыктан егылып төшеп, шунда ук җан биргән. 26 февральдә аның вафатына бер ел булды.**

**Рамилгә багышлап, апам исеменнән бәет чыгардым, чөнки мин туганымның кичерешләрен беләм, яхшы аңлыйм, аның кайгысын уртаклашам.**

## Рамил улыма

*Биш балама икешәр канат куеп,*
*Очырдым мин туган оядан.*
*Рамил улымны әҗәл, сиздермичә,*
*Алып китте якты дөньядан.*

*Урындыктан егылып төшү белән*
*Җаның чыккан секунд эчендә.*
*Нурияң белән газиз улыкаең*
*Ашыкканнар синең яныңа.*

*Күпме тырышканнар җан кертергә*
*Хәрәкәтсез яткан гәүдәңә.*
*Тырышулар нәтиҗә бирәлмәгән,*
*Җаның күчкән бакый дөньяга.*

*Үзеңнән алда балаңны күмүдән*
*Авыр хәлләр юктыр дөньяда.*
*Йөрәк януларын басар өчен,*
*Каян дәва табып чыдарга?*

*Биш көн элек кенә туган көнемә кайттың,*
*Саубуллашуың чыкмый уемнан.*
*Язмыш миңа нигәдер үч итеп,*
*Аерды мине газиз улымнан.*